ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Каинка торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2025 елның 21 ноябре №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Каинка торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Каинка торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 100% - СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары; 50% - 1 төркем инвалидлар; күпбалалы гаиләләр; көндезге уку йортлары студентлары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 2026 елда үзара салымны 3000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Каинка торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин